**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

____________　　　　31.05.2024 №ПР-98　　　　　　№ ___

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе "Тыннамас башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен бетерү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге, 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районының 2024 елның 28 маендагы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиясенең 30 нчы бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының 2024 елның 27 маенда уздырылган Тыннамас авылы гражданнары җыелышының 1номерлы беркетмәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе "Тыннамас башлангыч мәктәбе" белем бирү учреждениесен 2024 елның 31 июленнән бетерергә.
2. «Актаныш 1 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Тыннамас башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесенең документларын саклау һәм мөлкәтне кабул итү өчен җаваплы хокукый варисы итеп «Актаныш 1 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Тыннамас башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен бетерүче итеп, «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.М.Мансуровны билгеләргә.
4. «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.М.Мансуровка:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Актаныш 1 нче санлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр проекты әзерләргә;

хезмәт законнарына ярашлы рәвештә, бетерелә торган гомуми белем бирү учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе "Тыннамас башлангыч мәктәбе" белем бирү учреждениесен, тиешле хезмәтләрдә законда билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева